**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**О внесении изменений в Указ Президента Республики Татарстан «О Концепции развития и реализации интеллектуально-творческого потенциала детей и молодежи Республики Татарстан «Перспектива»**

В целях совершенствования деятельности Межведомственного координационного совета по реализации Концепции развития и реализации интеллектуально-творческого потенциала детей и молодежи Республики Татарстан «Перспектива», а также в связи с переходом отдельных лиц на другую работу и изменением наименований должностей **постановляю:**

1. Внести в Указ Президента Республики Татарстан от 9 октября 2012 года № УП-862 «О Концепции развития и реализации интеллектуально-творческого потенциала детей и молодежи Республики Татарстан «Перспектива» (с изменениями, внесенными указами Президента Республики Татарстан от 22 июня 2015 года № УП-570 и от 1 июля 2017 года № УП-596), следующие изменения:

а) в Положении о Межведомственном координационном совете по реализации Концепции развития и реализации интеллектуально-творческого потенциала детей и молодежи Республики Татарстан «Перспектива»:

в пункте 3:

в абзаце третьем слова «республиканских целевых программ» заменить словами «государственных программ Республики Татарстан»;

абзац четвертый изложить в следующей редакции:

«обеспечение взаимодействия органов государственной власти Республики Татарстан, органов местного самоуправления муниципальных образований Республики Татарстан (далее – органы местного самоуправления), общественных объединений и организаций при реализации Концепции;»;

в абзаце шестом слова «в Республике Татарстан (далее – органы местного самоуправления)» исключить;

дополнить абзацем седьмым следующего содержания:

«рассмотрение вопросов, связанных с совершенствованием деятельности и развитием республиканского центра выявления и поддержки одаренных детей и молодежи в Республике Татарстан, реализующего проекты совместно с Образовательным Фондом «Талант и успех»;»;

абзацы второй и третий пункта 4 изложить в следующей редакции:

«запрашивать в соответствии с законодательством информацию от

органов государственной власти Республики Татарстан, органов местного самоуправления, общественных объединений и организаций;

приглашать на свои заседания руководителей органов государственной власти Республики Татарстан, органов местного самоуправления, общественных объединений, организаций и должностных лиц.»;

пункт 6 дополнить предложением следующего содержания:

«Председателем Межведомственного координационного совета является Президент Республики Татарстан.»;

пункт 7 изложить в следующей редакции:

«7. Персональный состав Межведомственного координационного совета формируется из представителей органов государственной власти Республики Татарстан, органов местного самоуправления, общественных объединений и организаций.»;

пункт 9 изложить в следующей редакции:

«9. Заседания Межведомственного координационного совета проводятся ежегодно в соответствии с утверждаемыми планами работы. В случае необходимости могут проводиться внеочередные заседания Межведомственного координационного совета.

Заседание Межведомственного координационного совета ведет Председатель совета либо по его поручению один из его заместителей.»;

абзац второй пункта 12 изложить в следующей редакции:

«Решения Межведомственного координационного совета принимаются на его заседании простым большинством голосов от общего числа членов Межведомственного координационного совета и оформляются протоколом. При равенстве голосов голос председательствующего на заседании Межведомственного координационного совета является решающим. Решения Межведомственного координационного совета оформляются протоколами, которые подписываются Секретарем совета и утверждаются председательствующим на заседании Межведомственного координационного совета.»;

в пункте 15 раздела V:

абзацы третий и четвертый признать утратившими силу;

в абзаце седьмом слова «республиканских целевых программ» заменить словами «государственных программ Республики Татарстан»;

пункт 15 раздела VI считать пунктом 16;

пункт 16 считать пунктом 17 и изложить в следующей редакции:

«17. Организационно-техническое и информационное обеспечение деятельности Межведомственного координационного совета осуществляется Министерством образования и науки Республики Татарстан.»;

б) в составе Межведомственного координационного совета по реализации Концепции развития и реализации интеллектуально-творческого потенциала детей и молодежи Республики Татарстан «Перспектива» (далее – Совет):

вывести из состава Совета Ш.Х. Гафарова, М.М. Загидуллину,

А.А. Здунова, Э.Э. Искендерова, А.В. Песошина, А.М. Сибагатуллина, Т.Д. Сулейманова, Э.Н. Фаттахова, М.З. Шакирова, А.Ш. Ширинова, В.В. Шихобалова;

ввести в состав Комиссии:

Минниханова Рустама Нургалиевича – Президента Республики Татарстан, утвердив его председателем Совета;

Абдулганиева Фарида Султановича – министра экономики Республики Татарстан;

Аюпову Ираду Хафизяновну – министра культуры Республики Татарстан;

Выборнова Андрея Андреевича – начальника отдела высшего, среднего профессионального образования и науки Аппарата Кабинета Министров Республики Татарстан;

Габдрахманову Айгуль Тагировну – директора государственного бюджетного учреждения Молодежного центра «Сэлэт» Министерства по делам молодежи Республики Татарстан (по согласованию);

Губайдуллина Экзама Саматовича – председателя Совета муниципальных образований Республики Татарстан (по согласованию);

Киямова Руфата Рифгатовича – президента Региональной молодежной общественной организации «Лига студентов Республики Татарстан» (по согласованию);

Кондратьеву Аллу Андреевну – президента Региональной общественной организации «Академия творческой молодежи Республики Татарстан» (по согласованию);

Фаттахова Дамира Ильдусовича – министра по делам молодежи Республики Татарстан;

изложить в следующей редакции наименования должностей членов Совета:

И.Ю. Аминова – «генеральный директор акционерного общества «Телерадиокомпания «Новый Век», депутат Государственного Совета Республики Татарстан (по согласованию)»;

Р.Т. Бурганова – «заместитель Премьер-министра Республики Татарстан – министр образования и науки Республики Татарстан, заместитель председателя Совета»;

А.Г. Заляловой – «директор Казанского педагогического колледжа, председатель Совета директоров образовательных учреждений среднего профессионального образования Республики Татарстан (по согласованию)»;

В.А. Леонова – «министр спорта Республики Татарстан»;

О.Г. Синяшина – «директор Федерального исследовательского центра «Казанский научный центр Российской академии наук» (по согласованию)»;

В.Е. Туманина – «председатель исполнительного комитета Регионального молодежного общественного движения молодых ученых и специалистов Республики Татарстан (по согласованию)»;

Д.А. Туманова – «директор государственного бюджетного учреждения «Республиканский центр по поддержке творчески одаренных детей и

молодежи «Созвездие – Йолдызлык» (по согласованию)»;

С.В. Юшко – «ректор Казанского национального исследовательского технологического университета (по согласованию)».

2. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань, Кремль
25 мая 2019 года
№ УП-298

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Перспектива» Татарстан Республикасы балалар һәм яшьләрнең интеллектуаль-иҗади потенциалын үстерү һәм файдалану концепциясе турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

«Перспектива» Татарстан Республикасы балалар һәм яшьләрнең интеллектуаль-иҗади потенциалын үстерү һәм файдалану концепциясен гамәлгә ашыру буенча ведомствоара координация советы эшчәнлеген камилләштерү максатларында, шулай ук аерым затларның башка эшкә күчүе һәм вазыйфалар атамасы үзгәрүе белән бәйле рәвештә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Перспектива» Татарстан Республикасы балалар һәм яшьләрнең интеллектуаль-иҗади потенциалын үстерү һәм файдалану концепциясе турында» 2012 елның 9 октябрендәге ПУ-862 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2015 елның 22 июнендәге ПУ-570 номерлы һәм 2017 елның 1 июлендәге ПУ-596 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) «Перспектива» Татарстан Республикасы балалар һәм яшьләрнең интеллектуаль-иҗади потенциалын үстерү һәм файдалану концепциясен гамәлгә ашыру буенча ведомствоара координация советы турында нигезләмәдә:

3 пунктта:

өченче абзацта «республика максатчан программаларын» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт программаларын» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Концепцияне гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнары (алга таба – җирле үзидарә органнары), җәмәгать берләшмәләре һәм оешмаларның үзара хезмәттәшлеген тәэмин итү;»;

алтынчы абзацта «җирле үзидарә органнары (алга таба – җирле үзидарә органнары)» сүзләрен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле җиденче абзац өстәргә:

«Сәләт һәм уңыш» мәгариф фонды белән берлектә проектларны тормышка ашыручы Татарстан Республикасында сәләтле балалар һәм

яшьләрне ачыклау һәм аларга булышлык итү республика үзәгенең эшчәнлеген камилләштерү һәм аны үстерү белән бәйле мәсьәләләрне карап тикшерү;»;

4 пунктның икенче һәм өченче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, җәмәгать берләшмәләреннән һәм оешмалардан законнар нигезендә мәгълүмат соратып алырга;

үз утырышларына Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, җәмәгать берләшмәләре, оешмалар җитәкчеләрен һәм вазыйфаи затларын чакырырга.»;

6 пунктка түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«Ведомствоара координация советы рәисе булып Татарстан Республикасы Президенты тора.»;

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Ведомствоара координация советының персональ составы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, җәмәгать берләшмәләре һәм оешмалар вәкилләреннән формалаша.»;

9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Ведомствоара координация советы утырышлары расланган эш планнары нигезендә ел саен үткәрелә. Кирәк булганда, Ведомствоара координация советының чираттан тыш утырышлары үткәрелергә мөмкин.

Ведомствоара координация советы утырышын Совет рәисе яисә аның кушуы буенча урынбасарларының берсе алып бара.»;

12 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ведомствоара координация советы карарлары аның утырышында Ведомствоара координация советы әгъзаларының гомуми саныннан гади күпчелек тавыш белән кабул ителә һәм беркетмә белән рәсмиләштерелә. Тавышлар саны тигез булганда, Ведомствоара координация советы утырышында рәислек итүченең тавышы хәлиткеч санала. Ведомствоара координация советы карарлары беркетмәләр белән рәсмиләштерелә, аңа Совет секретаре кул куя һәм Ведомствоара координация советы утырышында рәислек итүче раслый.»;

V кисәкнең 15 пунктында:

өченче һәм дүртенче абзацларны үз көчен югалткан дип танырга;

җиденче абзацта «республика максатчан программаларын» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт программаларын» сүзләренә алмаштырырга;

VI кисәкнең 15 пунктын 16 пункт дип санарга;

16 пунктны 17 пункт дип санарга һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17. Ведомствоара координация советы эшчәнлеген оештыру-техник һәм мәгълүмати яктан тәэмин итү Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла.»;

б) «Перспектива» Татарстан Республикасы балалар һәм яшьләрнең интеллектуаль-иҗади потенциалын үстерү һәм файдалану концепциясен гамәлгә ашыру буенча ведомствоара координация советы (алга таба – Совет) составында:

Совет составыннан Ш.Х. Гафаровны, М.М. Заһидуллинаны, А.А. Здуновны, Э.Э. Искәндәровны, А.В. Песошинны, А.М. Сибагатуллинны, Т.Җ. Сөләймановны, Э.Н. Фәттаховны, М.З. Шакировны, А.Ш. Шириновны, В.В. Шихобаловны чыгарырга;

Совет составына кертергә:

Миңнеханов Рөстәм Нургали улын – Татарстан Республикасы Президентын, аны Совет рәисе итеп расларга;

Габделганиев Фәрит Солтан улын – Татарстан Республикасы икътисад министрын;

Әюпова Ирада Хафизҗан кызын – Татарстан Республикасы мәдәният министрын;

Выборнов Андрей Андреевичны – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының югары, урта һөнәри белем бирү һәм фән бүлеге башлыгын;

Габдрахманова Айгөл Таһир кызын – Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының «Сәләт» яшьләр үзәге дәүләт бюджет учреждениесе директорын (килешү буенча);

Гобәйдуллин Әгъзам Самат улын – Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы рәисен (килешү буенча);

Кыямов Руфат Рифгать улын – «Татарстан Республикасы Студентлар лигасы» төбәк яшьләр иҗтимагый оешмасы президентын (килешү буенча);

Кондратьева Алла Андреевнаны – «Татарстан Республикасы иҗат яшьләре академиясе» төбәк иҗтимагый оешмасы президентын (килешү буенча);

Фәттахов Дамир Илдус улын – Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министрын;

Совет әгъзалары вазыйфалары атамаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

И.Ю. Әминовның – «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» акционер җәмгыяте генераль директоры, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты (килешү буенча)»;

Р.Т. Борһановның – «Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры, Совет рәисе урынбасары»;

А.Г. Җәләлованың – «Казан педагогика көллияте директоры, Татарстан Республикасының урта һөнәри белем бирү мәгариф учреждениеләре директорлар советы рәисе (килешү буенча)»;

В.А. Леоновның – «Татарстан Республикасы спорт министры»;

О.Г. Синяшинның – «Россия фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәге» федераль тикшеренү үзәге директоры (килешү буенча)»;

В.Е. Туманинның – «Татарстан Республикасының яшь галимнәр һәм белгечләр төбәк яшьләр иҗтимагый хәрәкәте башкарма комитеты рәисе (килешү буенча)»;

Д.А. Тумановның – «Созвездие-Йолдызлык» иҗади сәләтле балаларга һәм яшьләргә булышлык күрсәтү республика үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе директоры (килешү буенча)»;

С.В. Юшконың – «Казан милли тикшеренү технология университеты ректоры (килешү буенча)».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2019 ел, 25 май
№ ПУ-298